РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
**СОВЕТ**
**Большекляринского**
**сельского поселения**
***Камско-Устьинского***
**муниципального района**

ул. Советская, 9,с. Большие Кляри, 422837
тел. (84377)32-2-42, факс: (84377) 32-2-42
ОКПО 04308901 ОГРН 1031638400364
ИНН/КПП 1622001763/162201001

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
***Кама Тамагы***
**муниципаль районы**
**Олы Кариле**
**авыл җирлеге**
**СОВЕТЫ**

Совет урамы, 9,Олы Кариле авылы, 422837,
тел. (84377)32-2-42, факс: (84377) 32-2-42
ОКПО 04308901 ОГРН 1031638400364
ИНН/КПП 1622001763/162201001

**12 декабрь 2021 ел** **№5**

**КАРАР**

**2022 нче елда Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районы Олы Кариле авыл җирлегенең Олы Кариле торак пунктында гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм алардан файдалану мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын билгеләү турында**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьясы, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районының Олы Кариле авыл җирлеге Уставының 24.1 статьясы нигезендә **карар бирәм**:

1. ТР , Кама Тамагы муниципаль районы, Олы Кариле авылы, Пионер урамы, 1 нче йорт адресы буенча урнашкан Олы Кариле авылы мәдәният йорты бинасында 2021 елның 22 декабрендә 14 сәгать 00 минутка, Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районы Олы Кариле авыл җирлегенең Олы Кариле торак пунктында үзара салым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыенының 1 этабын билгеләргә.
2. ТР , Кама Тамагы муниципаль районы, Олы Кариле авылы, Пионер урамы, 1 нче йорт адресы буенча урнашкан Олы Кариле авылы мәдәният йорты бинасында 2021 елның 22 декабрендә 16 сәгать 00 минутка, Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районы Олы Кариле авыл җирлегенең Олы Кариле торак пунктында үзара салым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыенының 2 этабын билгеләргә.
3. Гражданнар җыенына чыгарыла торган мәсьәләне расларга:

«2022 елда Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районының Олы Кариле авыл җирлеге территориясе, Олы Кариле авылында яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 500 сум күләмендә үзара салым кертүгә һәм алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияткә ия мәсьәләләрне хәл итү өчен юнәлдерүгә җибәрүгә килешәсезме:

- Олы Кариле авылында Колхоз, Штаб, Пионер, Фронтовиклар , Урман урамнары эчендәге юлларга вак таш түшәп төзәтү (вак таш ташу, таш салу, таш җәю, килешү буенча эшләр өчен түләү);

- Олы Кариле авылынында урамнарны яктырту объектларын карап тоту һәм аларга хезмәт күрсәтү (энергия саклаучы яктырткычлар, электр товарлары сатып алу);

- Олы Кариле авылында юлларны кардан чистарту, грейдлау (килешү буенча эшләр һәм хезмәтләр өчен түләү) ;

- Олы Кариле авылында җәйге чорда территориядәге чүп үләннәрен чабу (килешү буенча эшләр һәм хезмәт күрсәтүләр өчен түләү);

- Беларус 82.1 тракторын карап тоту (ягулык-майлау материаллары сатып алу һәм килешү буенча эшләр һәм хезмәтләр өчен түләү);

- Олы Кариле авылы обелискын ремонтлау (Бөек Ватан сугышында һәлак булучыларның исемлеген яңарту, килешү буенча, эш һәм хезмәтләр өчен түләү)

- янгын депосын һәм автоцистернаны тоту (АЦ-40 (131) өчен ягулык-майлау материаллары, запас частьләр сатып алу, килешү буенча эшләр һәм хезмәтләр өчен түләү.

« ӘЙЕ» «ЮК».

4.Гражданнар җыенын үткәрү өчен авыл җирлегендә яшәүчеләрнең исемлеген бүлү тәртибе:

а) беренче этапта эш (хезмәт) графигы кемгә мөмкинлек бирә, кем эш көннәрендә катнаша ала, шул яшәүчеләр катнашалар.

б) икенче этапта эш (хезмәт) графигы эш көннәрендә катнашырга мөмкинлек бирмәгән яки шәхси (гаилә) шартлары аркасында катнаша алмаганнар катнаша ала.

5. Әлеге карарны түбәндәге адреслар буенча урнашкан мәгълүмат стендларына урнаштыру юлы белән игълан итәргә (бастырып чыгарырга):

-ТР, Кама Тамагы районы, Олы Кариле авылы, Пионер урамы, 1;

-ТР, Кама Тамагы районы, Чаллы авылы, Ленин урамы, 43;

-ТР, Кама Тамагы районы, Кече Кариле авылы, Вахитов урамы, 16, шулай ук Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында бастырып чыгарырга һәм Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районының рәсми сайтында «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә 10 көн эчендә урнаштырырга.

6. Әлеге карар аның басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

**Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районы Олы Кариле авыл җирлеге башлыгы** **Ф.Г. Гарифуллин**